ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОКУВАКСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ КУАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2021 елның 27 октябре | Иске Куак | № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Иске Куак җирлегенең Иске Куак авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 21 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәттә катнашучылар,тыл хезмәтчәннәре, сиксән яшьтән өлкән гражданнар һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру һәм сусткәргечләрне алыштыру.
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге - төзекләндерү һәм вак таш салу

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы,7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы И.Н.Сушкова